**Тема:** Ямьсез холыклар. Ялган һәм хәйлә (1-5 сыйныф).

**Максат:**
1.Укучыларны "Ямьсез холыклар. Ялган һәм хәйлә" дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп, тормышта гадел була белергә ярдәм итү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
3. Гаделлек, ялган турында төшенчә бирү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- "Намуслы кеше ул – туры сүзле һәм кыю кеше" икәнең белү, намуслы булырга тырышу.
- "Ялган- гонахларның күлмәге- алар аның белән капланып яшеренәләр" икәнен аңлау.
- "Ялган – кешене гөнаһка, ә гөнаһ исә җәһәннәмгә илтә" икәнен белү, ялганнан ерак булырга тырышу.

**Эпиграф:** ***Ялган оят китерер, дөреслек куәт китерер.***

**Дәрес барышы.**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Бер патша үзенә хезмәтчене сайлаганда, матур, көчле, бөтен яктан килгән колга кызыгып, аны сатып алмакчы була. Шулвакыт сатучы патшаны кисәтә: бу кол тырыш,эшне җиренә җиткереп эшли- эшләвен, ләкин аның бер кечкенә генә кимчелеге бар: ул да булса кирәк, егетнең ялганчы булуы. Патшаның аның алдакчы булганга исе китми: "Эшен эшләсә- ялганы әллә нинди зыян китермәс әле",- диеп колны сатып ала һәм ялгышмый, чөнки хезмәтчесе кушканны, әйтеп бөтергәнче диярлек, башкарып куя. Патшаның яраткан хатыны да аны мактап бетерә алмый.*

*Көннәрнең бер көнне кол- егет аңа болай диеп әйтә: "Патша инде сине хәзер яратмый, икенче хатынга өйләнмәкче була, ләкин төнлә аның бүлмәсенә кереп чәчен киссәң, сихерче ярдәмендә мәһабәтен кире кайтарырга була". Шул ук вакытта кол патшага хатыны аны яратмавы һәм бүген төнлә бүлмәсенә кереп патшаны үтерергә хәзерләнү турында хәбәр итә.*

*Төнлә патша- бикә кайчы тотып ире янына керә. Аңа таба үрелгәндә, патша аны пычак белән чәнчеп үтерә.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... ("Ялган һәм хәйлә ")
-

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. Төркемнәрдә эш**

**1нче бирем** "***Сүзлек***"

-Нәрсә ул алдау? (1. Хәйләләү, хәйләләп нәрсәсен дә булса алу; кешене авыр хәлдә калдыру; кешегә начарлык эшләү. 2. Ялганлау, ялган сөйләү. 3. Ялган сөйләп кешене ялгыштыру, ялгыш фикергә китерү, ялганга ышандыру).

- Нәрсә ул ялган? (Хакыйкатьне бозып күрсәтә торган, дөрес булмаган, чын булмаган.- ялган хәбәр, ялган караш, ялган хис).

- Нәрсә ул хәйлә? (Хәйлә - 1.Нинди дә булса эштә мәкер, астыртынлык. 2. Берәр максатка ирешү өчен уйлап чыгарылган ялган сылтау, сәбәп, гәмәл).

- Алдау, ялган һәм хәйлә сүзләре арасында уртаклык бармы? (Бар, әлбәттә. Хәйлә төшенчәсе урыны белән алдауны да, ялганны да үз эченә ала.

**2нче бирем *Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"*** (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).
- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез.

- Алдашсаң –абруең китәр, тиргәшсәң – ... *кадерең китәр.*
- Намус җаннан … кадерле.
- Ялган сөйләмәсәң ... *үкенечтә булмассың.*
- Ялган сөйләсәң – ... тотылырсың, дөрес сөйләсәң – ... *котылырсың.*
- Намуслы йөз … *ояла.*
- Намусыңны яшьтән үк ... *сакла.*
- Кешенең хөрмәтлелеге ... *үз кулында.*
- Кеше алдында кем дә гөл, кеше артында намус ... *бел.*
- Казан карасы китә, намус ... *карасы китми.*
- Вөҗдан (намус) хасталыгы тән хасталыгыннан ... *куркынычрак.*
- Вөҗдансыз кеше үзәксез агач шикелле: үзлегеннән ... *аварга тора.*

- Кайсы мәкаль хикәянең эчтәлегенә күбрәк туры килә?

**3 нче бирем *"Хикәягә исем кушу".***
- Хәзер дәреснең башында укылган хикәягә кайтыйк. Хикәягә 2 исем кушыгыз:
1се- аның темасын ачыкласын ("Ялган", "Ялган һәм кеше язмышы").
2се- хикәянең идеясын, төп фикерен күрсәтсен ("Ялган- хәсрәтнең чыганагы")
- Ни өчен патша хатыны үлә?
- Аның үлемендә кем гаепле? (Явыз алдакчы кол, ялганчы кешегә уйламыйча ышанган патша һәм аның хатыны).
- Димәк, ялган бик куркыныч нәтиҗәгә китермәсен өчен, без һәрбер сүзгә уйламыйча, аның дөреслеген тикшермичә ышанырга тиеш түгел.

**4 нче бирем *"Безнең киңәшләр"***

- Гадел, тугры бул, вәгъдә иткәнне үтә.
- Һәрвакыт дөреслекне генә сөйлә- дусларың күп булыр.
- Иптәшләреңне, алдыйм диеп, мыскыл итмә- ялгыз калырсын.
- Ямьсез эшләрне эшләмә- аларны яшерергә, кешеләрне алдарга туры килер.
- Һәр бер сүзгә ышанма, аны сөйләргә ашыкма- нахак белән кешене рәнҗетерсен**.**
- Көндәлек эшкә нәтиҗә ясап бар: кешеләрне үпкәләтмәдем ме, алдамадым мы, хәйләкәр булмадым мы.
- Аллаһы Тәгалә яраткан тугры, намуслы, гадел кешеләрдән бул.

- Алдакчы, ялганчы, хәйләкәр кешенең капма каршысы кем була? (Намуслы, гадел, тугры кеше).

**5 нче бирем** ***“Намуслы кеше ул – туры сүзле һәм кыю кеше”***

- Намуслы кеше ялганчыдан нәрсә аера? (Намуслы дип без хәйлә, куркаклык һәм ялган белән үзен пычратмаган кешене әйтәбез).

- Намуслы кеше ул – туры сүзле һәм кыю кеше.
- Дуслыкның кадерен белә торган, якыннарын, таныш-белешләрен һәм хәтта таныш түгел кешеләрне дә хөрмәт итә, ярата торган кеше.
- Әдәпле һәм намуслы кеше соңыннан оят булырдай, ата-аналарына, дусларына сиздерергә ярамаган эшләр эшләмәскә тырыша. Чөнки алардан яшереп эшләгән эш икейөзлелек, хәйләкәрлек булыр иде. Ә бу сыйфатлар кешене алдашырга, куркаклыкка өйрәтә.
- Намуслы кеше, дусларының уңышын күреп, үзе дә шатлана белә. Беркайчан да, беркемнән дә көнләшми.
- Намуслы кеше әти-әнисе, әби-бабасы хезмәтегнең дә кадерен белә. Үзе дә эш сөя. Намуслы кешегә һәрвакыт таянырга була. Шуңа күрә андый кешене хөрмәт итәләр, аңа ышашалар.
- Намуслы кеше ояла белә, диләр. Чөнки ул үз гаебен, хатасын, кимчелекләрен таный, аларны ясаганы өчен кызара, үкенә белә һәм төзәтү юлларын эзли.
- Намусны саклау – бигрәк тә кыз балалар өчен яшьтән белергә тиешле сыйфат. Кызлар горурлыгы ул тәкәбберлек, үз-үзен генә ярату, масаю түгел. Ул – үз кадереңне, җәмгыятьтә, кеше арасында үз урыныңны белү.

**3. Интернетка сәяхәт.**

***а) Ә син ничек уйлыйсың?***

**-** Дәрескә әзерләнгән вакытта Интенет сайтларына тагын кереп чыктык. Ә анда бүгенге дәрес темасына шулай ук төрле карашлар.

***- Мәсъәлән, берәү яза:*** *“Кая карасаң да- ялган”.*

- Икенчесе: *“Ни өчен дер гадел, намуслы дусны табу бик авырайды- бөтен җирдә алдау һәм сатлык җаннар”.*

**- Аңа җавап итеп язганнар:**

*“Болай уйлаган очракда шулай булачак та. Дөньяга икенче төрлерәк карасаң- барысы да үзгәрәчәк. Кешенең язмышы, дуслары- аның үз кулында.*

- Чыннанда, үзең нинди- дустың да шудый. Ә кайбер чакта синең тирәдә ялганчылар күбәю- Аллаһы Тәгаләнең сынау булырга мөмкин: үзең дә сатлыкҗан, алдакчы түгел микән диеп. Ә син ничек уйлыйсың? Күңелдән генә бу сорауга җавап эзләп кара әле.

- Безнеңчә, кешенең гаделсезлеген күргәч: **мин үзем гадел микән** дип улану бик урынлы булыр иде.

***б) Ялган күңелдә пычрак эзләр калдыра***

- Бер сайтта менә нинди фикергә тап булдык:

- *Ялган- бөтен гонахларның каны- алар аның белән туклыналар.*
- *Ялган- гонахларның күлмәге- алар аның белән капланып яшеренәләр.*
- *Ялган- безнең гонахларыбызның нәҗесләре, пычрагы: без алдаган кешеләрнең һәм үзебезнең күңелләребездә гомер буена ябышып калган җирәнгеч эзләр.*

- Ни өчен ялган бөтен гонахларның каны белән чагыштырыла? (Чөнки ялкау да, карак та, сатлык җан да- барысы да гонах кылганда, ялганны кан урынына кулланалар, ялган белән “тукланалар”).

- Ни өчен ялган гонахларның күлмәге? (Чөнки начар эшне яшерер өчен кеше ялганлый).

- Ни өчен ялган безнең күңелләребездә җирәнгеч, пычрак эзләр калдыра? (Чөнки ялган юкка чыкмый, күңелләребездә пычрак эз калдырып кала).

**4. Бер экспериментның нәтиҗәсе.**

Интернет- газета “Дейли телеграф” яза:

*Бу экспериментта ике группага бүленгән 18 яштән алып 71 яшкә кадәр 110 кеше катнаша. 1нче группа 10 атна буена кечкенә генә булса да ялганнан баш тартырга тиеш була. 2нче группа алдаудан тыемый, гәдәттәгечә яши (алдап- ялганлап, хәйлә корып). Атна саен кешеләрнең “дөреслекне” яки ялган сөйләүләрен “Детектор лжи” дигән аппарат тикшереп бара. Нәтиҗәдә- гәдәткә кергән ялганчылыктан баш тарту кешенең физик һәм психик сәламәтлеген күпкә яхшырта.*

- *Инглиз галимнәре шундый нәтиҗәгә килгәннәр:* ***ялган кешенең саулыгына бик зур зыян китерә, ә гаделлек аның сәламәтлеген күпкә яхшырта.***

**5. Изге Коръән китабыннан.**

- Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип боера:

- ***«…Ялган сүздән сакланыгыз”*** («Хаҗ” сүрәсе, 30нчы аять).
- ***«Әй, мөэминнәр, Аллаһтан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен сөйләгез”*** («Әхзәб” сүрәсе, 70нче аять).
- ***«Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә һәр эштә гадел булырга, изге гамәлләр кылырга һәм якын туганнарның хакын үтәргә боерадыр. Аллаһ сезне фәхеш, бозык һәм начар эшләрдән, тыядыр»*** (“Нәхел” сүрәсе: 90).

- Аллаһ Тагәлә һәр нәрсәдә дә гадел булырга әмер итә. Беренчедән, Аллаһка карата гаделлек. Аның бер Үзенә генә гыйбадәт кылу, Аның әмерләренә буйсынып яшәү иң олуг гаделлекнең берсе булып тора. Шулай ук кешеләргә дә карата да гадел булырга куша. Моңа изгелекләр кылу, туганнар хакын үтәү, туганлык җепләрен саклау керә. Аннары, яхшы гамәлләргә өндәгәч, барлык бозыклыклардан тыя. Бу Ислам диненең максаты — яхшыллыка чакыру, начарлыктан тыю.

**6. Хәдисләр.**

- Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләре үзенең бер хәдисендә әйткән:

- ***«Аллаһның колы ялганны сөйләгән вакытта шушы гөнаһның җирәнгеч исеннән фәрештәләр чакрым ярым ераклыкка кача”.***
- ***«Ялган – кешене гөнаһка, ә гөнаһ исә җәһәннәмгә илтә. Әгәр кеше даими рәвештә ялганласа, ул Аллаһы Тәгалә каршында ялганчы булып язылыр”.***

- Ялганчы башкаларга түгел, ә үзенә зыян китерә. Аның бөтен ялган сүзләре үзенә каршы юнәлтелгән. Кеше ялган сөйләгәндә, анардан фәрештәләр ерагая бара. Ялган кешене гөнаһка китерә, аннары – җәһәннәмгә. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтте:

- ***«Аллаһның колы ялганлаган вакытта, аның күңелендә кара тап барлыкка килә. Аннан соң бу таплар күбәя һәм калеб тулысынча шушы таплар белән каплана. Шундый кеше Аллаһ каршысында ялганчы булып языла”.***

- Ялган – кешенең кальбен (күңелен) каралта һәм хак юлда аңа киртә булып тора.

– Сафуан бин Сүләйм (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) дигән сәхабәдән риваять ителә: Аллаһның расүле галәйһиссәләмнән сорадылар*: «Йә расүлуллаһ, мөселман куркак булырга мөмкинме?” «Әйе, мөмкин”, – диде Пәйгамберебез галәйһиссәләм». “Мөселман саран булырга мөмкинме?” – дип сорадылар». “Әйе, мөмкин”, – дип җавап бирде Пәйгамберебез галәйһиссәләм. «Мөселман ялганчы булырга мөмкинме?” – дип янә сорадылар. «Юк, беркайчан була алмый”, – диде Расүл Әкрам галәйһиссәләм (Мәлик бин Әнәс, Муватта, Бәйһәкый).*

- Бу хәдистән күренгәнчә, иман белән ялган калебтә бергә була алмыйлар. Иманлы кеше кайвакыт куркак һәм саран булса да, ялган аңа бер дә килешми, чөнки ялган мөселман сыйфаты түгел. Мөселман куркак һәм саран да булырга тиеш түгел, ләкин бу сыйфатлар ялган белән чагыштырганда андый ук куркыныч түгел. Әлбәттә, хак мөселман шушы өч сыйфаттан пакъ булырга тиеш. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм:

- ***«Сез минем беркайчан да саран, ялганчы һәм куркак булуымны күрмәссез", – дигән*** *(Бохари).*

**7. Ислам динендә кайбер хәлләрдә ялганларга рөхсәт ителүе:**
- бер-берсе белән сөйләшмәгән ир белән хатынны яки ике мөселманны килештерер өчен;
- сугышта дошманны алдар өчен;
- кемнең булса да җанына, малына, диненә һәм намусына золым һәм хаксызлык белән зарар килгәндә, аларны коткарыр өчен;
- хаста кешеләргә өмет һәм яшәү көче бирер өчен.
- Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм бер хәдисендә шулай дигән:
«Халыкның арасын төзәтер өчен изге максат белән сүз йөрткән яки изге ният белән ялган сөйләгән кеше ялганчы түгелдер".

**8. Эпиграф белән эш.**

***"Ялган оят китерер, дөреслек куәт китерер"***
- Бу сүзләрне дәреснең эпиграфы. Сез аларны ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/

**IV. Рефлексия.**
- Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?
- Аннан сез нинди нәтиҗәләр ясадыгыз?
- Дәрес кайсы ягы белән файдалы булды?
- Җөмләне дәвам итегез: "Димәк, ялган кешегә зыян китерә, чөнки..."

**V. Өйгә эш бирү**. "Ни өчен дустың ялганчы булуын теләмисен?" дигән темага җавап әзерләү.